**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә**
**муниципаль район Советы**
**КАРАРЫ**

**“ 08” нче ноябрь 2018 нче ел** **№ 42-246**

**“Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2017 нче елның 14 нче декабрендәге 31-182 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча җирле нормативларга үзгәрешләр кертү турында”**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФК нче номерлы Федераль кануны, 2010 нчы елның 25 нче декабрендәге “Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында” 98-ТРК нче номерлы Татарстан Республикасы Кануны, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 нче елның 29 нчы сентябрендәге 84 нче номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2017 нче елның 14 нче декабрендәге 31-182 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча җирле нормативларга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 5.2.14 нче пунктның 5 бүлеге 5.2 бүлекчәсендә беренче кызыл юлда “чикләрен” сүзен алырга;

икенче кызыл юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Автомобиль юлларының юл буе полосалары турында нигезләмә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана”;

5.2.18 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5.2.18. Автомобиль юлының юл буе полосалары чикләрендә капиталь төзелеш объектлары, юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән объектлар, юл сервисы объектлары, реклама конструкцияләре, мәгълүмат щитлары һәм күрсәткечләр урнаштыру автомобиль юлы хуҗасының язма рәвештә ризалыгы булганда рөхсәт ителә. Бу ризалыкта мәҗбүри үтәлергә тиешле техник таләпләр һәм шартлар булырга тиеш.

Әгәр капиталь төзелеш объектын урнаштыру өчен территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү таләп ителсә, мондый объектны автомобиль юлының юл буе полосасы чикләрендә урнаштыруны күздә тоткан территорияне планлаштыру буенча документлар расланганчы автомобиль юлы хуҗасы белән килештерелә. Бу

ризалыкта мәҗбүри үтәлергә тиешле техник таләпләр һәм шартлар булырга тиеш. Шул ук вакытта әлеге пунктның беренче кызыл юлында күрсәтелгән автомобиль юлының юл буе полосасы чикләрендә объектны төзү, реконструкцияләүгә рөхсәт алу таләп ителми.

Автомобиль юлының юл буе полосасы чикләрендә объектлар төзүгә, реконструкцияләүгә ризалык турында белдерү тәртибе һәм сроклары, автомобиль юлының юл буе полосасы чикләрендә капиталь төзелеш объектын урнаштыруны күздә тота торган документлар яки мондый объектны төзүне, үзгәртеп коруны килештерүдән баш тарту турында, территорияне планлаштыру буенча документлар, шулай ук мондый баш тарту өчен нигезләр федераль кануннар белән билгеләнә.

Гомуми мәйданы 10 мең кв.метрдан артык булган автомобиль юлларына тоташтырылган стационар сәүдә объектлары транспорт чаралары туктальшлары һәм туктау урыннары, шулай ук автомобиль юлыннан аларга үтү мөмкинлеген тәэмин итү максатларында керү, чыгу юллары һәм якын килү җайланмалары белән җиһазландырылырга тиеш. Автомобиль юлын башка автомобиль юлына тоташтырганда, керү һәм чыгу юллары кучмә-тиз йөрешле полосалар белән һәм юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү максатларында автомобиль юлын төзекләндерү элементлары белән җиһазландырылырга тиеш".

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталының" "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru. һәм Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/.бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының экология, җирдән файдалану, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм территорияләрне төзекләндерү буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль**
**Районы Башлыгы** **Козлов В.М.**